ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**05.10.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 2540**

«2017 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрү тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы (29.07.2017 ред.), «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ номерлы (03.07.2016 ред.), «Россия Федерациясендә җәмәгать контроле нигезләре турында» 2014 елның 21 июлендәге 212-ФЗ номерлы (03.07.2016 ред.) Федераль законнарга ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2017 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрү тәртибен расларга.
2. Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге башлыгына әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, Интернет челтәрендә хокукый мәгълүматның рәсми порталында ( http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Житәкче А.Х. Сәхибуллин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты
2017 елның 05 октябрендәге
2540 номерлы карарына
Кушымта

«2017 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрү тәртибе

1.Әлеге Тәртип 2017 елга Зеленодольск районы территориясендә заманча шәһәр мохитен формалаштыру муниципаль программасы проекты (алга таба - муниципаль программа) буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрү формасын, тәртибен һәм срокларын билгели.

2.Муниципаль программа проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышу түбәндәге максатларда үткәрелә:

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы гражданнарын, оешмаларын һәм иҗтимагый берләшмәләрен муниципаль программаның эшләнелгән проекты турында мәгълүмат бирү;

- муниципаль программаның эшләнелгән проекты турында Татарстан Республикасы Зеленодольск районы гражданнарының, оешмаларының, берләшмәләренең фикерен ачыклау һәм исәпкә алу.

3.Муниципаль программа проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышу муниципаль программаның җаваплы башкаручысы тарафыннан оештырыла һәм үткәрелә. Җәмәгатьчелек белән фикер алышу Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының яңа программаны раслау турындагы карары проектына карата гамәлгә ашырыла.

4.Җәмәгатьчелек белән фикер алышуларда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә яшәүче 18 яшькә җиткән гражданнар, шулай ук оешмалар һәм иҗтимагый берләшмәләр, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр вәкилләре, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкилләре катнаша.

5.Муниципаль программа проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышу муниципаль программа проектын Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында ачык урнаштыру рәвешендә гамәлгә ашырыла.

6. Җирле үзидарә органнары, сәяси партияләр һәм хәрәкәтләр, иҗтимагый оешмалар, башка затлар вәкилләреннән мондый фикер алышуны оештыру, кызыксынган затларның тәкъдимнәрен комиссия бәяләвен үткәрү, шулай ук программаны раслаудан соң аны билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыруны контрольдә тоту өчен иҗтимагый комиссия булдыру.

7. Муниципаль программа проектын урнаштырганда түбәндәге мәгълүмат бастырыла:

7.1. Муниципаль программа проектының җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрү турында әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтадагы формада каралганча хәбәр итү.

7.2. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрү срогы муниципаль программа проекты Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында урнаштырылган көннән алып 30 көн тәшкил итә.

7.3.Муниципаль программа проектына карата искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җибәрү өчен муниципаль программаның җаваплы башкаручысының электрон адресы.

7.4.Иҗтимагый комиссия составы.

8. Җәмәгатьчелек белән фикер алышуда катнашучыларга муниципаль программа проектына карата искәрмәләр (тәкъдимнәр) җибәргәндә гражданның фамилиясен, исемен, әтисенең исемен һәм туган көнен, яисә оешманың, иҗтимагый берләшмәнең, җирле үзидарә органының исемен, шулай ук оешма, иҗтимагый берләшмә, җирле үзидарә органы вәкиленең фамилиясен, исемен һәм әтисенең исемен күрсәтергә кирәк. Юкса, муниципаль программа проектына карата искәрмәләр(тәкъдимнәр) аноним дип таныла һәм карауга кабул ителми.

9.«Зеленодольск муниципаль районының заманча шәһәр мохитен формалаштыру» муниципаль программасына кертү турында гражданнарның, оешмаларның тәкъдимнәрен карау һәм бәяләү комиссиясе муниципаль программа проектын җәмәгатьчелек белән фикер алышуы кысаларында килгән искәрмәләрне (тәкъдимнәрне) карый, гомумиләштерә, анализлый. Искәрмә (тәкъдим) максатка ярашлы һәм нигезле булган очракта, муниципаль программаның җаваплы башкаручысы муниципаль программа проектын эшләп бетерә.

Җәмәгатьчелек белән фикер алышу нәтиҗәләре рекомендация характерында. Искәрмәләр булмаган очракта, муниципаль программа проекты үзгәрешсез кала бирә.

10.Муниципаль программа проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышу нәтиҗәләре муниципаль программа проектын җәмәгатьчелек белән фикер алышу срогы тәмамланганнан соң 7 эш көне эчендә муниципаль программаның җаваплы башкаручысы тарафыннан әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтага ярашлы рәвештә йомгаклау документы (протокол) рәвешендә формалаштырыла һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

«2017 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите формалаштыру» муниципаль программасы проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышу тәртибенә
1 нче кушымта

# Муниципаль программа проекты буенча җәмәгатьчелек белән фикер алышуны үткәрүне хәбәр итү

«_____________________________________________________________
___» муниципаль программа проекты турында фикер алышу._______________________________ (муниципаль программаның җаваплы башкаручы исеме, электрон почтасы һәм муниципаль программаның җаваплы башкаручысының контакт телефоны) «________________» муниципаль программа проектын учреждениенең , оешманың, предприятиенең, иҗтимагый берләшмәләрнең барлык кызыксынучы затларына, эшмәкәрләргә тикшерүдә катнашырга тәкъдим итә.

Документ проекты белән бирелгән (муниципаль программа проектына сылтама) Җәмәгатьчелек белән фикер алышу __________дан_____________ кадәр үткәрелә. Җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү максатында әлеге документка карата искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кертүне сорыйбыз. Искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне ______________________ электрон почтага җибәрүне сорыйбыз: (муниципаль программаны үтәүченең электрон почтасы), тел.________________ (муниципаль программаны җаваплы башкаручының контактлы телефоны).

«2017 елга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә заманча шәһәр мохите булдыру» муниципаль программасы проекты буенча җәмагатьчелек белән фикер алышуны үткәрү тәртибенә
2 нче кушымта

«_______________________________________________________________
_____________________________________________» муниципаль программа проекты буенча җәмагатьчелек белән фикер алышу нәтиҗәләре буенча беркетмәсе № ____

_______________ (дата) Зеленодольск шәһәре

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның _______________ №____ карары таләпләре нигезендә «2017 елга Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының заманча шәһәр мохитен булдыру муниципаль программасы проекты буенча җәмагатьчелек белән фикер алышуны үткәрү тәртибен раслау турында» __________________________________ (муниципаль программаның җаваплы башкаручысының исеме)«_____________________________________________» муниципаль программа проекты буенча җәмагатьчелек белән фикер алышу оештырылды һәм уздырылды . Киресенчә булган очракта «___________________________________________» муниципаль программа проекты буенча җәмагатьчелек белән фикер алышуны үткәрү срогы дәвамында түбәндәге искәрмәләр һәм тәкъдимнәр керде:

1.________________________________________________________________
2.________________________________________________________________

Искәрмәләр һәм тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләре:

1.________________________________________________________________
2________________________________________________________________

Яки «__________________________________________» муниципаль программа проекты буенча җәмагатьчелек белән фикер алышуны үткәрү срогы дәвамында __________________________________________ (муниципаль программаның җаваплы башкаручысының исеме) искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Муниципаль программаны җаваплы башкаручы җитәкчесенең имзасы

Беркетмәне алып барды
____________ (имза)